**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Казаклар Чаллысы авыл җирлеге составына керүче Иванай авыл торак пунктында гражданнар җыены турында**

**КАРАР**

12 ноябрь, 2025 ел № 1

2025 елның 20 мартындагы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 33-ФЗ номерлы Федераль законы , “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 октябрендәге 14 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башлыгының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Иванай авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2025 елның 31 октябрендәге 3 номерлы карары нигезендә, 2025 елның 12 ноябрендә узган гражданнар җыенының 1 нче номерлы йомгаклау беркетмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Иванай авылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Казаклар Чаллысы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм 1 төркем нвалидлардан, мобилизациялэнгэн гражданнар һәм аларнын гаилә әгзаларыннан гайре 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә күләмендә үзара салым кертергә. Тупланган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- торак пунктлар чиклэрендэ жирле әһәмияттәге гомүми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, хезмәт күрсәтү

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- . су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү

манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең Иванай авылы, Калинин урамы, 18 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче –
Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башлыгы Ф.Х.Хәсәншин